# Сочинение язу үрнәге

## Кереш.

- Текст “ ........................................ ” дигән сүзләр белән тәмамлана.
- Тексттан алынган әлеге юлларда төп фикер әйтелгән.
  Автор бу текстта (туган җирне сагыну; табигатьне саклау; табигатьне ярату; кешеләр арасындагы дуслык; әниләрне ярату; бала белән ана мәхәббәте; туганнарның бер-берсенә булышуы; батырлык эшләү; олы кешеләргә карата игътибарлы булу; туган телне белүнең кирәклеге; туган җирнең кадерле, якын булуы һ.б турында яза.

### Төп өлеш

2.(Дөрестән дә, туган җир һәркем өчен кадерле;
Чыннан да, табигатьне сакларга кирәк;
Минемчә, әниләр безнең өчен иң кадерле, якын, газиз кеше;
Минем уйлавымча, дуслык һәрбер кеше өчен бик кирәк ул.
Чыннан да, батырлыкны һәрвакыт эшләп була;
Дөрестән дә, туган телне һәркем белергә тиеш һ.б
(Автор бу җөмләдә туган җирнең сулары да тәмле, кырлары да ямьле була, дип яза; Автор бу җөмләдә табигатьтәге һәр нәрсәнең кирәклеген искәртә; Автор бу җөмләдә әниләрнең безнең өчен борчылулары (шатланулары) турында яза; Автор бу җөмләдә туган телне белергә кирәклек турында яза; Автор бу җөмләдә дуслыкның авыр вакытта сыналуы турында яза һ.б. )
Нәтиҗәләремне раслау өчен, бирелгән тексттагы (4 нче) җөмләдән мисал китерәм.

**Йомгаклау.**

3. Әйтелгәннәремне гомумиләштереп, шундый фикергә килергә мөмкин. ( Төп фикерне 1-2 җөмлә белән язарга!!!- Әйе, туган җиребезне сакларга, аны яратырга кирәк; Әйе,табигатькә карата һәркем игътибарлы булырга тиеш;
Әйе, һәрбер кеше табигатьне сакларга тиеш;
Әйе, әниләребезнең кадерен алар исән вакытта белергә кирәк; Әйе, олыларның киңәшләрен һәрвакыт истә тотарга кирәк; Әйе, авырлыклар алдында каушап калырга ярамый;
Әйе, кешеләрне бервакытта да рәнҗетергә ярамый һ.б.-
Минем фикерләрем белән һәрбер кеше килешер иде дип уйлыйм.